**КАРАР**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

Тымытык авылы № 95-156 «14» апрель 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының кайбер карарларын гамәлдән чыгару турында

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон һәм муниципаль хокукый актларны муниципаль хезмәт турындагы гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан

Тымытык авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

- 2017 елның 18 октябре 59-44 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен бушлай нигездә катнашу (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;

- 2019 елның 17 апреле 76-120 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Советының 2017 елныц 18 октябре 59-44 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак (сәяси партиядән тыш) коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен бушлай рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» карары.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис